Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**18 октябрь 2022 ел** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 18 октябрендә 14 сәгатьтә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пункты террито-риясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакы-тлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен фай-далануга ризамы":

1. Су белән тәэмин итү (насослар сатып алу, суүткәргеч линияләрен ремонтлау).
2. Урам яктырту өчен утлар сатып алу.
3. Кичкетаң авылы урамнарын кардан чистарту (ягулык-майлау материалларын сатып алу).
4. Янгын куркынычсызлыгы беренчел чараларын тәэмин итү. (янгын сүндерү машинасы өчен запчастьләр сатып алу).
5. Рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.
6. Кичкетаң авылында күперне ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 359 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 220 кеше, бу – 61,2% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 58 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кичкетаң торак пунктында

гражданнар җыенын узган дип таныйрга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип таныйрга.

2. 2023 елда Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» Кичкетаңторак пункты территориясендә, I төркем инвалидларыннан, ялгыз картлардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган затлардан һәм шәхесләрдән тыш ирektән мәхрүм итү урыннарында булганнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Су белән тәэмин итү (насослар сатып алу, суүткәргеч линияләрен ремонтлау).

2. Урам яктырту өчен утлар сатып алу.

3. Рөхсәтсез чүплекләрне бетерү, Кичкетаң авылы урамнарын кардан чистарту (ягулык-майлау материалларын сатып алу).

4.Янгын куркынычсызлыгы беренчел чараларын тәэмин итү. (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запчастьләр сатып алу, хезмәт хакы).

5. Кичкетаң авылында күперне ремонтлау.

6. Кичкетаң авылында төзекләндерү, аншлаг ясау буенча башка чаралар.

7. Кичкетаң авылында гомуми файдаланудагы юлларга ремонт ясау (Кичкетаң авылы эчендәге юлга вак таш сатып алу һәм салу.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р. НУРИЕВ

Совет Кичкетанского сельского поселения
Кичкетаң авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002452